
Газета МБОУ «АСОШ №2»


# Пульс школы

# Мәктәп пульсы



## 12 апреля - День космонавтики

№8
Апрель, 2025 г.




Ежегодно 12 апреля люди отмечают памятную дату, посвященную первому полету человека в космос — День космонавтики. В этот день хочется пожелать чистого и ясного неба, космических просторов счастья и вдохновения. Пусть звезды указывают верный путь к успеху, пусть каждый день радует новыми открытиями, крутыми взлетами к облакам сокровенных мечтаний души и сердца! Желаем счастье будет размером с космос, любовь — как огромная галактика, а настроение — воздушным и легким. С великим праздником, с Днем космонавтики!

Ел саен 12 апрельдә кешеләр кешенең космоска беренче очышына багышланган истәлекле датаны - Авиация һәм космонавтика көнен бәйрәм итәләр. Бу көнне  илебез күгендә тынычлык булсын,  космик киңлекләр бәхет һәм илһам китерсен дип телибез. Йолдызлар уңышка дөрес юл күрсәтсеннәр, көн саен яңа ачышлар туып, жанның һәм йөрәкнең яшерен хыялларын тормышка ашырырга булышсыннар. Һәркемнең бәхете космос, мәхәббәте - зур галактика кебек, ә кәефе - яхшы һава торышы кебек булсын.  Космонавтика көне белән!

**В этом выпуске:**



| | |
|---|---|
| Милләтемнең рухи юлбашчысы | 2 |
| Тукай яши безнең йөрәкләрдә | 3 |
| Кыңгыраулы мәктәп еллары | 4 |
| Из школьной жизни... | 5 |
| Страница юного поэта... | 6 |
| Эковесна в действии! | 6 |

# Миллəтемнең рухи юлбашчысы



**Без сугышта юлбарыстан көчлебез,**
**Без тынычта аттан артык эшлибез.**
**Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? —**
**Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук!**

*Г.Тукай*

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның күренекле шəхес икəнлеге турында уйланганда, мин иң элек, нəкъ менə татар милләте, татар халкы өчен эшлəгəн эшлəре, язган шигырьлəрен əйтергə телим. Шагыйрь үз туган илебез килəчəген кайгыртып, башкаларның да шəм-лампа кебек үз тирəсен генə яктыртырга тиеш түгеллеген əйтə. Шагыйрь өчен миллəткə бəйле булган сораулардан да зуррак, мөһимрəк нəрсə була алмаган. Көндəлек тормыш тудырган мəсьəлəлəр дə алар янында бик вак булып калганнар. «Үз-үземə» шигыреннəн алынган юллар язганнарымны тагын да ныгыта:

Күңел берлəн сөям бəхтен татарның,
Күрергə шаһлыгын, тəхтен татарның.
Татар бəхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дə чын татармын.

Бу шигырь юллары аның туган миллəтебезгə булган мөнəсəбəтен дəлиллəп тора. Тукай халкыбыз рухында мəңге яшəячəк, чөнки халык рухы аның əсəрлəренə бик тирəнтен кереп урнашкан. Əнə бит “Əллүки”, “Тəфтилəү”, “Зилəйлүк”, “Туган тел” кебек җырлары шулкадəр халыклашты, аларны нəкъ менə Тукай иҗат иткəне сизелми дə. “Туган тел”е аеруча еш яңгырый. Күп кенə əдəби кичəлəр, хəтта төрле җыеннар да шушы җыр яңгыравы белəн тəмамлана. Халкыбыз гимнына əверелгəн “Туган тел”не барлык иллəрдə яшəүче татар баласы укый һəм көйли.

Белгəнебезчə, Г. Тукай – милли шагыйрь. Халкыбызның гореф-гадəтлəрен, бəйрəмнəрен, бай телен, сəнгатен чын күңелдəн яраткан башка шагыйрь бармы икəн тагын? Ул бары миллəтем, халкым дип эшлəгəн һəм яшəгəн. Кечкенəдəн татар халкының ачы язмышын күреп, газапларын үз җилкəсендə тоеп үскəнгəдер, халкыбыз тормышын, проблемаларын шигырьлəренə тирəнтен яшергəн. Шуңа күрə дə иҗатын туган халкына хезмəт итүгə багышлаган.

Минемчə, шагыйрьнең “Фикер” гəҗитендə (1906 ел) басылган бер мəкалəсендə халкыбызны иң борчыган мəсьəлəлəрнең берсе - татарларда укыту системасының арттальгы турындагы язманы мисалга китереп тə, аның никадəр халыкчан шагыйрь икəнен дəлиллəп булыр иде. Бу язмада ул милли мəгариф язмышы темасын күтəреп кенə калмый, аны алга җибəрү юлларын эзли.

Халык арасында дан казанган, татар халкының тормышын, язмышын үзенең шигырьлəренə шулай тирəнтен яшерүе, иң беренче чиратта, аның каян килеп чыкканына бəйледер. Кечкенə Апуш булып, сабый чагыннан ук ятимлектə, өйдəн-өйгə күчеп йөреп яшəгəн, кечкенəдəн татар халкының ачы язмышын күреп, газапларын үз җилкəндə, үз тəнендə татып үскəн шагыйрь иң түбəннəн өскə үрмəлəп, бөек Тукай булган. Ни генə булмасын, сабыйлыкта үз канаты астына аны халкым сыендырган. Аннан яклау да, саклау да тапкан шагыйрьнең иҗатында халкым тормышы бөтен тулылыгы белəн ачыла. Үзенең бөтен иҗади көчен туган халкыбызга хезмəт итүгə, аны миллəт буларак аклауга һəм үстерүгə багышлаган Бөек Тукай - безнең татар əдəбиятына салынган таза, ныклы нигезебез.

Дымлы апрель җиле исə. Тукай шул җиллəргə кушылып нидер əйтə кебек... Бик күп мəктəп, аудиториялəрдə, театр сəхнəлəрендə, мəдəният сарайларында, клубларда, радиоларда өзлексез яңгырап, безнең уй-тойгыларыбызны яңартып, яшəүгə, хезмəткə, иҗатка илһамландыра, көрəшкə чакыра Тукаебыз.

***Мəликə** Җəлəева, 9 А сыйныфы укучысы*

# Тукай яши безнең йөрәкләрдә

***Вакыт безне 1913 нче елның апрель көннәреннән ераклаштырган саен, Тукай безгә тагын да якыная...***

***Яздан аерып булмый Тукайны!***
***Язда килгән, язда ул янган.***
***Язы, киләчәге барлар ничек китсен,***
***Ничек югалалсын дөньядан.***

***Яз җиткәч, халкыбыз бөек шагыйребезнең туган көнен билгеләп үтә.***

***Г. Тукай дөньяда бары тик 27 ел гына яшәгән, бары 8 ел гына иҗат иткән. Шулай булса да, ул гаять зур, бәя биреп бетермәслек рухи байлык калдырган. Аның тормышы һәм иҗаты - халкыбыз тарихында иң якты, иң изге сәхифәләрнең берсе. Балачактан күңелебезгә кергән Тукай безне гомеребез буена озата бара.***



## Кушлавыч

Бөдрә таллар үсә Кушлавычта
Көмеш сулы чишмә янында.
Тамырлары тирән, нык торалар,
Баш имиләр җилдә, давылда,
Ә кайвакыт ямансулый алар,
Ботаклары җиргә салына.
Хәтерлидер бәлки узганнарны,
Сагынадыр алар, сагына
Нәни Габдулланы. Сабый чакта
Ул бит шул талларга сыенган,
Ялан тәпи басып боз өстенә,
Авыз иткән чишмә суыннан.
Шушы җирдә яшәп, шушы җирдә
Туфрак булган җиде бабасы.
Бик еракта аның нәсел башы,
Биш гасырдан арта арасы.
Ирек сөйгән батыр халык салган
Кушлавычның нигез ташларын.
Төпләнгәннәр алар, качып килеп-
Каһәреннән явыз патшаның.
Иген иккән халык гомер буе
Җирне ашлап ачы тир белән.
Уртак булган язмыш, авырлыкны
Күтәргәннәр алар ил белән.
Алгы сафка баскан ир-егетләр
Яу килгәндә Рәсәй өстенә.
Ватан өчен барган сугышлардан
Читтә калмаганнар берсе дә.
Кушлавычта изге һәр адым җир,
Кырларына куна торналар.
Бөдрә таллар Тукай суын эчкән
Чишмәләрне саклап торалар.
Чишмәләр күп монда, чишмәгә бай
Тукай туган авыл – Кушлавыч.
Күп гасырлы узган тарихы бар,
Киләчәге аның соклангыч…

***Әнәс** Галиев, Кушлавыч авылында туган фронтовик шагыйрь*



# Кыңгыраулы мәктәп еллары...

Минем мәктәптә иң истә калганы – классташларым белән Казанга бару. Бик күңелле мизгелләр булып истә калды ул экскурсияләр. Без тагын да дуслаштык һәм бергә вакыт үткәрдек. Казанга килеп, без бик күп яңалык белдек, тарих белән таныштык. Бигрк тә шәһәрнең матурлыгы безне тан калдырды. Иң кызыклысы, күргәзмәдә һәм кинотеатрда булу иде. Аннан гел уңай тәэсирләр алып, шатланып кайта идек. Бу елны да күп истәлекләр калдырды. Дусларыбыз белән бергә үткәргән вакыт – болар барысы да безнең дуслыгыбызны тагын да ныгытып, искиткеч хатирәләр бүләк итте.

Казанга сәяхәтләр безнең хәтердә һәрвакыт саклаанр.

*__Диана__ Бирючевская, 11 нче сыйныф укучысы.*

Кыңгыраулы мәктәп еллары Мәктәп еллары һәркемнең иң кызыклы вакытыдыр, мөгаен. Бу вакытны бөтенебез җылылык белән искә төшерә. Минем өчен сыйныф белән Казанга бару иң мавыктыргыч көн булгандыр. Бу көнне без мультимедиа күргәзмәсендә булдык. Әлеге күргәзмә Италия рәссамы тормышына багышланган. Без бик күп фотосурәтләр ясадык. Күрзгәзмәдән соң без “Kazan Mall” сәүдә үзәгенә бардык. Анда мин беренче тапкыр синнабон ашадым. Миңа бик ошады. Шулай ук бу үзәктә без фильм карадык. Бу экскурсиядә безнең белән бик кызык хәл булды: укытучыбызны югалттык. Без аны 20 минут буе эзләдек һәм ул ниһаять табылды. Әмма без электричкага соңга кала яздык. Ул вакытта без физкультура дәресендә дә аның кадәр тиз чапмыйбыз дип уйладык. Бу экскурсия миңа бик ошады. Без вакытны күңелле итеп үткәрдек.

*__Илүзә__ Шәмсемөхәммәтова, 11 нче сыйныф укучысы.*

Мәктәптә үткән 11 ел минем хәтеремдә тирән эз калдырды. Әниемнең, миңа ике озын толым үреп, чәчәкләр бәйләме белән мәктәпкә беренче тапкыр озата барганы бүгенгедәй хәтеремдә. Беренче уку көнем бик матур башланды. Өйгә бирелгән эш тә минем хәтеремдә әле. Бик тырышып кояш рәсемен ясап буядым да исемемне язып куйдым. Айгөл Талгатовна биргән белем миңа мәктәп елларында алыштыргысыз база булды. Бишенче сыйныфта без инде бераз олыгайдык, яңа укытучылар белән таныштык. Алар да безгә төпле белем бирделәр. Миңа тарих дәресләре ошый иде, чөнки анда без үткәннәр белән таныштык, һәм бу мине сөендерде. Урта мәктәптә уку процессында күп нәрсә булды: күтәрелү дә, төшү дә, елау да, күз яшьләре дә. 9 нчы сыйным минем өчен мәктәп тормышында иң җаваплы мизгелләрнең берсе булгандыр. Булачак имтиханнарны сайлау, сыйныфташлар белән үткән күңелле кичәләр матур бер мизгелбулып истә калган. Кайбер классташлар белән аерылышу кыен булды, ләкин алар белән дә очрашу, аралашу дәвам итә. 10 нчы сыйныфка мин ниндидер дулкынлану белән бардым, чөнки күпләр белән яхшы таныш түгел идем. Нәтиҗәдә, сыйныф дус, тату булып чыкты, мондый атмосферада уку рәхәт иде. Ә 11нче сыйныфны тәмамлагач, минем белән нинләр буласы әлегә билгесез. Шулай да күңелле үзгәрешләр булыр дигән өмет бар. Киләчәктә кем буласымны уйлыйм да, күңелдә дулкынлану барлыкка килә, билгеле. Кайвакыт, минем тормышымның бу этабы тиздән бетәчәгенә үкенеп тә куйгалыйм. Алда имтиханнар... Барлык классташларыма уңышлар телим. Түземсезлек белән көкән нәтиҗәләр яхшы буласына шигем юк, чөнки алдына максат куеп укый, тырыша сыйныфташларым.

*__Гүзәлия__ Фәттахова, 11 нче сыйныф укучысы.*



# Из школьной жизни...



25 апреля в нашей школе произошло знаменательное событие — торжественное открытие Аллеи Славы активистов школы! В открытии принимали участие директор школы Г.Г.Гиниатуллина, администрация школы, классные руководители и родители Здесь увековечены имена победителей и призёров олимпиад, спортивных соревнований, конкурсов и социальных проектов — тех, кто прославляет нашу школу, район и республику своими достижениями и победами. Аллея украшена рябинами, и их алые ягоды — как символ памяти: они напоминают нам о крови, пролитой героями в годы Великой Отечественной войны. Эта аллея — не только дань уважения нашим активистам, но и связь поколений, ведь она посвящена 80-летию Великой Победы. Это наш вклад в сохранение памяти о подвиге поколения победителей и вдохновение для новых свершений! Гордимся каждым из вас и верим, что впереди ещё больше ярких побед!

**Выставка «Их имена названы улицы нашего города»**




В нашей школе начальные классы оформили уникальную выставку, приуроченную к празднованию 80-й годовщины Победы в Великой Отечественной войне 1941–1945 годов.

23 апреля в рамках проекта «Мин Арча баласы» состоялась квест-игра «Мин Арчаны беләм». Учащиеся 9А класса Галямшина Лейсан, Шарафиева Лилия и ученик 10 класса Абдуллин Ренат приняли активное участие в игре.



24 апреля прошел районный этап областного конкурса юных инспекторов движения «Безопасное колесо». Соревновались ребята в знаниях правил дорожного движения, основ безопасности жизнедеятельности, оказании первой медицинской помощи, правил дорожного движения, фигурном вождении велосипеда, конкурсе агитбригад. В общекомандном наша школа заняла 8 место! Поздравляем!



# Страница юного поэта...

**Птицы весной**

Весенний воздух полон пенья,
Звенит мелодия с небес.
Пернатых звонкое волненье
Разносит ветер через лес.

Синицы, ласточки, скворцы —
Вернулись все в родные гнёзда.
Весны воздушные гонцы
Поют, пока сияют звёзды.

Малиновка в ветвях берёз
Выводит трели на рассвете.
Её мотив, как капли рос,
Прозрачен, чист на всей планете.

Грачи хлопочут у полей,
Их крики — будто разговоры.
А соловей среди ветвей
Ведёт с луной ночные споры.

Щегол, нарядный как цветок,
Мелькает в зелени весенней.
И дятла чёткий молоток
Стучит в лесу без сожаленья.

Кукушка мерит жизни срок,
Считает годы, не скупится.
А жаворонок, как пророк,
В лазурном небе серебрится.

Весна идёт, весна поёт
Устами птиц многоголосых.
И каждый звук, как мёд, течёт,
Будя траву в прохладных росах.

**Земля**

Проснулась Земля от зимнего сна,
Лучами согрета, теплом полна.
Сбросила белый, холодный наряд,
И свежестью дышит весенний сад.

Капели звенят, как хрустальный звон,
Ручьи зажурчали со всех сторон.
Подснежник несмело глядит в окно,
Где солнце сияет уже давно.

Деревья одели зелёный шёлк,
И ветер весенний к нам в гости пришёл.
Он песню поёт о приходе весны,
О том, как прекрасны весенние дни.

Птиц перелётных вернулся отряд,
Их трели повсюду с утра звучат.
Природа проснулась, ликует душа,
Как жизнь на Земле весной хороша!

Поля зеленеют под синью небес,
Листвою шумит пробудившийся лес.
Цветы распускаются день ото дня,
В объятьях весны оживает Земля.

Всё дышит, цветёт и стремится расти,
Чтоб летом плоды и нектар принести.
Весна — это время надежд и мечты,
Пора пробужденья и чистой любви.

***Эльвира** Насифуллина, 7А класс*



## Эковесна в действии!

В рамках 4-й недели «Твои действия» республиканского конкурса #Эковесна2025 наша школа провела масштабный субботник!

Дружно убрали закреплённую территорию. Собрали мусор и привели участок в порядок. Каждый внёс свой вклад в заботу о природе.


***Редактор*** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Дизайнер - верстальщик*** Гузелия Фаттахова
***Фотокорреспондент*** Илюза Шамсемухаметова
***Корректор*** Гузелия Фаттахова
***Редколлегия*** Камилла Мифтахова

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15
***Сайт школы:*** ***https://edu.tatar.ru/arsk/sch2***